# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Күк-Тәкә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**10 ноябрь 2025 ел** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"27.10.2025 ел, № 2 карары нигезендә 2025 елның 10 ноябрендә узган Күк-Тәкә авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре белән Күк-Тәкә авылы гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Күк-Тәкә авылының «Ачы» чишмәсен киртәләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 181 кеше кертелгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 126.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 117, «КАРШЫ» позициясе өчен 9 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

“Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу

акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-җир асты суларыныц табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Күк-Тәкә авылыныц «Ачы» чишмәсен киртәләү).”

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт; Күк-Тәкә авылы, Ленин ур., 40 нчы йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http://aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштырып халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районынын Тымытык авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Мостафина